**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«11» июнь 2026 ел** **№ 48**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство белешмәләре турында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы «Пространство мәгълүматларының милли системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» карары, Нурлат муниципаль районы Уставының 54 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 14 мартындагы 27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.41 пунктчаны өстәргә:

«3.41. Үз вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Палата дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын файдаланырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев